РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

13.08.2021 — № 974-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 25 июнендәге 710-п номерлы карары белән расланган, дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрдән яки җир кишәрлегеннән, җир кишәрлекләре бирмичә, сервитут, гавами сервитут билгеләмичә, файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Саба муниципаль районы прокуратурасының Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 25 июнендәге 710-п номерлы карарына булган 2021 елның 5 августындагы 02-08-01-88 номерлы протестын караганнан соң, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “Дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрдән яки җир кишәрлегеннән, җир кишәрлекләре бирмичә, сервитут, гавами сервитут билгеләмичә, файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында” 2021 елның 25 июнендәге 710-п номерлы карары белән расланган, дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрдән яки җир кишәрлегеннән, җир кишәрлекләре бирмичә, сервитут, гавами сервитут билгеләмичә, файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** 1.3.4 пунктында “бирелергә мөмкин” сүзләрен “бирелә” сүзенә алмаштырырга;

**1.2.** 1.3.4 пунктындагы икенче абзацның өченче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Мөрәҗәгать телендә җавап бирү мөмкин булмаган очракта, Россия Федерациясенең дәүләт теле кулланыла”;

**1.3.** 2.7.3 пунктында “кабул ителергә мөмкин” сүзләрен “кабул ителә”

сүзенә алмаштырырга.

**2.** Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М.Р. Ишниязов